РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ЧИСТОПОЛЬСКИЙ ГОРОДСКОЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

***Постановление*** ***Карар***

**29.03.2019** **г.Чистополь** **№ 51**

**Норматив хокукый актларга үзгәрешләр кертү турында**

Чистай шәһәр прокуратурасының 26.03. 2019 елгы 02-08-02-2019нчы һәм 27.03. 2019 елгы № 02-08-02-2019нчы таләпләрен карап, ришвәтчелек факторларын бетерү максатында

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чистай шәһәре башкарма комитетының 2017 елның 7 ноябрендә кабул ителгән “2017 елга шәһәр маршрутларында Чистай шәһәре халкына хезмәт күрсәтү буенча автотранспортта пассажир ташулары хезмәте күрсәтүгә килешү төзү хокукына ачык конкурс оештыру һәм үткәрү турында”гы 221 нче карары үз көчен югалткан дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чистай шәһәре башкарма комитетының 2018 елның 26 октябрендә кабул ителгән “2019-2021 елларга шәһәр маршрутларында Чистай шәһәре халкына хезмәт күрсәтү буенча автотранспортта пассажир ташулары хезмәте күрсәтүгә килешү төзү хокукына ачык конкурс оештыру һәм үткәрү турында”гы 249 нчы карары белән расланган шәһәр маршрутларында Чистай шәһәре халкына хезмәт күрсәтү буенча автотранспортта пассажир ташулары хезмәте күрсәтүгә килешү төзү хокукына ачык конкурс үткәрү буенча Конкурс комиссиясе турындагы Нигезләмәгә (1нче кушымта) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4.13нче пункт үз көчен югалткан дип танырга;

2) 4.16нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: “Конкурс комиссиясе гаризасы конкурс документациясе таләпләренә тәңгәл килми торган Дәгъвачыга конкурста катнашуга рөхсәт бирүдән баш тарту турында карар кабул итә. Дәгъвачыга әлеге карарны кабул иткән көннән соң килә торган көннән соң килүче көндә катнашуга рөхсәт бирүдән баш тарту турында белдерү җибәрелә”.

3. Чистай шәһәре башкарма комитетының ТКХ, төзелеш, транспорт, энергетика, элемтә һәм юл хуҗалыгы бүлегенә әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүматлар порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыруны тәэмин итәргә һәм Татарстан РеспубликасыЧистай муниципаль районы башкарма комитетының рәсми сайтында (chistopol.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне үз өстемдә калдырам.

Җитәкче И.Ф. Рәхимов